**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**

**Министерство образования и науки Республики Татарстан**

**МКУ « Исполнительный комитет Высокогорского района Республики Татарстан»**

**МБОУ "Казакларская ООШ"**

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
|---|---|---|
| на заседании ШМО учителей начальных классов | заместитель директора школы по учебной работе | Директор |
| Руководитель ________________ ИсхаковаГ.Х | ________________ Халикова Р. Р. | ________________ Исхаков Г. Р. |
| Протокол № 1 от « 28» август 2023 г. | « 28 » август 2023 г. | Приказ № 81 от «28» август 2023 г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

**учебного предмета «Родной (татарский) язык»**

для обучающихся 1-4 классов

на 2023-2024 учебный год

**с. Казаклар, 2023**

**Укыту предметын үзләштерүнең шәхси, метапредметлы һәм предметлы нәтиҗәләре**

Бирелгән программа буенча укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр

**I сыйныф.**

Укучылар башкара алырга тиешле эшләр:
- баш һәм юл хәрефләрен, аларны тоташтыручы сызыкларны һәм сүзләрне ачык итеп, бозмыйча язу;
- басма, язма хәрефләр белән бирелгән сүз һәм җөмләләрне дөрес күчереп язу;
- әйтелеше белән язылышы туры килгән сүзләрне, шундый сүзләрдән төзелгән 3-5 сүзле җөмләләрне ишетеп дөрес язу;
- җөмләнең беренче сүзен баш хәреф белән башлап, җөмлә беткәч, нокта (өндәү, сорау) куеп язу.
- телдән 4-5 җөмләле кечкенә хикәяләр төзү.

1 классны тәмамлаганда, укучылар татар телендәге барлык аваз һәм хәрефләрне гамәли танып белергә, аваз белән хәрефнең төп аермасын практик аңлауга ирешергә тиеш;
сүзләрне авазларга таркату, авазларны сүздәге тәртиптә әйтү;
сузык һәм тартык авазларны һәм аларның хәрефләрен аерып таный белү;
калын һәм нечкә сузыкларны дөрес әйтү;
сүзләрне иҗекләргә бүлү;
җөмләләрне сүзләргә таркату;
баш һәм юл хәрефләрен, аларны тоташтыручы сызыкларны һәм сүзләрне ачык итеп, бозмыйча язу;
басма, язма хәрефләр белән бирелгән сүз һәм җөмләләрне дөрес күчереп язу;
әйтелеше белән язылышы туры килгән сүзләрне, шундый сүзләрдән төзелгән 3-5 сүзле җөмләләрне ишетеп дөрес язу;
җөмләнең беренче сүзен баш хәреф белән башлап, җөмлә беткәч, нокта куеп язу;
хәрефләрнең график яктан дөрес язылышын, сүздә аларны тоташтыру ысулларын;
хәрефләрне дөрес тоташтырып, ритмлап иҗекләр, сүзләр, кечкенә җөмләләр язу;
кечкенә текстларны тактадан, дәреслектән дөрес итеп (иҗек һәм хәрефләрне төшереп калдырмый, урыннарын алмаштырмый, хәреф формаларын бозмыйча), сүзләп күчереп язу;
әйтелеше белән язылышы туры килгән сүзләрдән төзелгән җөмләләрне ишетеп язу (диктант);
э,о,ө,й,е,ю,я хәрефләре, йө,йо кушылмалары булган сүзләрне дөрес язу; кеше исем, фамилияләрен, хайван кушаматларын, җөмлә башындагы сүзләрне баш хәрефтән язу.

**2 нче сыйныф**

-сүзләрне,җөмләләрне, 30-40 сүзле текстны, хәрефләрен бозмыйча, төшереп калдырмыйча, хәреф өстәмичә, урыннарын алыштырмыйча, аңлаешлы, пөхтә итеп, каллиграфик дөрес язу
-сузык һәм тартык авазларны, калын һәм нечкә сузыкларны икеләнүсез аеру, анализ ясау, бирелгән теориягә таянып, аларга анализ ясау,бирелгән аваз схемасына,характеристика тиешле авазлар, сүзләр сайлау.
-сүзләрне иҗекләргә бүлү һәи иҗекләп юлдан-юлга күчерү, бә-рәң-ге, бәрәң-ге, бә-рәңге
- Кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл ,елга, исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.
-е,в,г,й,к,н,ң,о,ө,х,һ,э,ю,я хәрефләре, ый, йо,йө кушымчалары булган сүзләрне дөрес язу
-янәшә килгән бертөрле ике тартык аваз хәрефләре булган әллә, кәккүк.Габбас кебек сүзләрне, нечкә(калын) аеру билгесе кергән гади, программада булган сүзләрне (дөнья, ашъяулык) дөрес язу һәм юлдан –юлга күчерү

-сүзгә фонетик анализ ясау, иҗекләргә бүлү,авазларны сүздәге тәртиптә ачык, дөрес әйтеп атап чыгу,
-үзең язганны бирелгән үрнәк белән чагыштыру
-сүзләргә дөрес сорау кую һәм шуның нигезендә предметны ,предметның эшен,хәрәкәтен, билгесен, өстәмә предметны ,ярдәмче сүзләрне таба белү
-җөмләнең баш кисәкләрен таба бел-уку,уеннар, көндәлек тормыш, җәнлекләр, кош-кортлар турындагы темаларга 4-5 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп сөйләү һәм язу
сүзләрнең әйтелешен, кулланышын, язылышын истә калдыру: аваз,авыз, елга, бәрәңге, бияләй, борын, вакыт,гомер, гыйнвар, дөрес, дүшәмҗе, җавап, җомга,җөмлә,җылы,йөрәк,караңгы,көньяк,кыңгырау,маңгай,Мәскәү,муен,оньк,оя,пәнҗешәмбе,савыт, сәгать,, сәлам, сеңел, тавык,тавыш, тәмле, төньяк, уен, уңыш,хайван,хөрмәт,һава,һаман,чаңгы,чәршәмбе,чия,шәһәр,шуа,эссе,юан,якшәмбе.

**<u>3 сыйныф.</u>**

Укучылар белергә тиеш:
-сүзнең мәгънәле кисәкләре: тамыр һәм кушымча, ясагыч кушымча, төрләндергеч кушымча;
- сүз төркемнәре: исем, сыйфат, фигыль, кисәкчә, бәйлек.
- җөмләнең баш кисәкләре: ия һәм хәбәр.
- җөмләнең иярчен кисәкләре (төрләргә бүлмичә)
Укучылар башкара алырга тиеш:
-үтелгән орфограммалар (калын һәм нечкә сузыклар, яңгырау һәм саңгырау тартыклар, парсыз тартыклар, нечкәлек һәм аеру билгеләре, кушма һәм парлы сүзләр, тамырда авазлар чиратлашуы, кисәкчәләр) кергән 55 – 60 сүзле текстны, җөмлә ахырында тиешле тыныш билгеләрен куеп, диктант итеп язу.
-текстларны грамоталы һәм каллиграфик дөрес күчереп язу.
- сүзләрне төзелеше ягыннан тикшерү(тамыр һәм кушымчаларны аеру, кушымчаларның төрен билгеләү, тамыр, ясалма, кушма һәм парлы сүзләрне аерып күрсәтү).
- сүз төркемнәрен һәм аларның грамматик билгеләрен тану, аеру (исемнең санын, килешен, фигыльнең затын, заманын);
- берлек сандагы исемнәрне килеш белән төрләндерү
- фигыльне заман формаларына куя белү.
-текстта синонимнарны һәм антонимнарны таный, сөйләмдә куллана белү.
-сораулар ярдәмендә җөмләдә сүзләрнең бәйләнешен билгеләү, сүзтезмәләрне аеру; сүзтезмәдәге ияртүче һәм иярүче сүзләрне аеру.
- җөмлә тикшерү (төрен билгеләү, баш һәм иярчен кисәкләрне аера белү)
- бергәләп төзегән план буенча 70 – 85 сүзле изложение язу.
- текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү.
- текстны мәгънәле кисәкләргә бүлү, кызыл юлны саклау.
- текстның мәгънәле кисәкләре, җөмләләр арасында бәйләнеш булдыру.
- темасыннан яки төп фикереннән чыгып, текстка исем кую.
- хикәяләү, тасвирлау һәм фикер йөртү характерындагы текстларны аера белү.
- шәхси тәҗрибәгә, сюжетлы картинага таянып (алдан әзерлек белән), сочинение язу.
- фикер йөртү характерындагы җавап төзеп әйтү.

**4 сыйныф.**

Укучылар белергә тиеш:
-сүзнең мәгънәле кисәкләре: тамыр һәм кушымча, ясагыч кушымча, төрләндергеч кушымча;
- сүз төркемнәре: исем, сыйфат, фигыль, кисәкчә, бәйлек, рәвеш.
- җөмләнең баш кисәкләре: ия һәм хәбәр, җөмләнең иярчен кисәкләре
Укучылар башкара алырга тиеш:
-үтелгән орфограммалар (калын һәм нечкә сузыклар, яңгырау һәм саңгырау тартыклар, парсыз тартыклар, нечкәлек һәм аеру билгеләре, кушма һәм парлы сүзләр, тамырда

авазлар чиратлашуы, кисәкчәләр) кергән 75-80  сүзле текстны, җөмлә ахырында тиешле тыныш билгеләрен куеп, тиңдәш кисәкләр янында тиешле тыныш билгеләрен дөрес куеп диктант итеп язу.
-текстларны грамоталы һәм каллиграфик дөрес күчереп язу.
- сүзләрне төзелеше ягыннан тикшерү(тамыр һәм кушымчаларны аеру, кушымчаларның төрен билгеләү, тамыр, ясалма, кушма һәм парлы сүзләрне аерып күрсәтү).
- сүз төркемнәрен һәм аларның грамматик билгеләрен тану, аеру (исемнең санын, килешен, фигыльнең затын, заманын);
- берлек сандагы исемнәрне килеш белән төрләндерү
- фигыльне заман формаларына куя белү.
-текстта синонимнарны һәм антонимнарны таный, сөйләмдә куллана белү.
-сораулар ярдәмендә җөмләдә сүзләрнең бәйләнешен билгеләү, сүзтезмәләрне аеру; сүзтезмәдәге ияртүче һәм ияртүче сүзләрне аеру.
- җөмлә тикшерү (төрен билгеләү, баш һәм иярчен кисәкләрне аера белү)
- бергәләп төзегән план буенча 90-95  сүзле изложение язу.
- текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү.
- текстны мәгънәле кисәкләргә бүлү, кызыл юлны саклау.
- текстның мәгънәле кисәкләре, җөмләләр арасында бәйләнеш булдыру.
-  темасыннан яки төп фикереннән чыгып, текстка исем кую.
- хикәяләү, тасвирлау һәм фикер йөртү характерындагы текстларны аера белү.
- шәхси тәҗрибәгә, сюжетлы картинага таянып (алдан әзерлек белән), сочинение язу.
- фикер йөртү характерындагы җавап төзеп әйтү.

**Универсаль уку гамәлләре формалаштыру**

**Татар теленнән башлангыч гомуми белем бирү баскычын (1–4 сыйныфлар) тәмамлаган укучы:**

Башлангыч гомуми белем бирү баскычында татар теле фәнен өйрәнү нәтиҗәсендә укучыларда белем алу осталыгы нигезе буларак танып белү, коммуникатив, регулятив һәм шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре формалашачак.

**Танып белү универсаль уку гамәлләре**

Укучылар өйрәнәчәк:

• мөһим бәйләнешләрне аерып чыгару нигезендә кагыйдә формалаштырырга;
• күнегүләрне мөстәкыйл эшләү алымнарын үзләштерергә;
• тәкъдим ителгән план буенча телдән аңлатырга;
• материаль объект, таблица, рәсем, схемалар, сүзлекләр кулланырга;
• бирелгән алгоритм буенча күнегүләр башкарырга;
• фикерләүдә логик чылбыр төзергә;
• уку мәсьәләләрен модельләштерүдә билгеләр (символлар) кулланырга.

*Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:*

• *интернетны кулланып, мәгълүмат эзләргә;*
• *мөстәкыйль рәвештә нигезләмә һәм критерийлар сайлап, чагыштыру, сериация һәм классификация башкарырга;*
• *сәбәпле-нәтиҗәле мөнәсәбәтләр урнаштыруны үз эченә алган логик хикәяләү төзергә.*

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре**

Укучылар өйрәнәчәк:

• партадаш күрше белән яисә төркемдә хезмәттәшлек итәргә;
• нинди дә булса предмет яисә объектка төрле карашлар булу мөмкинлеген аңларга;
• килешергә һәм уртак эшчәнлектә гомуми чишелешкә килергә;
• сораулар формалаштырырга.

*Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:*

• *сораулар ярдәмендә партнердан өстәмә мәгълүмат алырга;*
• *монолог төзергә.*

**Регулятив универсаль уку гамәлләре**

Укучылар өйрәнәчәк:
- таблица буенча кагыйдәнең дөреслеген тикшерегә;
- кагыйдә, инструкцияләрне истә тотарга һәм шуларга ияреп гамәлләр кылырга;
- максатка кагылышсыз гамәлләрдән тыелырга;
- сәбәпле-нәтиҗәле бәйләнешләр урнаштырырга.

*Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:*
- *партадаш күршең белән хезмәттәшлектә яңа уку мәсьәләләрен куярга;*
- *уку эшчәнлегенең үзең өчен әһәмиятен, мәгънәсен һәм сарыф ителгән вакытны, көчне бәяләргә;*
- *ирешeләчәк нәтиҗәне алдан фаразларга;*
- *яңа уку мәсьәләсен чишүгә керешкәнче үз мөмкинлекләреңне мөстәкыйль бәяләргә.*

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре**

Укучыларда формалашачак:
- татар теле фәненә танып белү кызыксынуы;
- дәреслек геройларына һәм партадаш күршеңә ярдәм итү инициативасы;
- үз уңышларың/уңышсызлыкларыңның сәбәпләре турында фикер йөртү;
- нормалардан тайпылышны күрү.

## Укыту программасының эчтәлеге

### Татар теленнән гомуми программа

### Сөйләм эчтәлеге

Тыңлап аңлау. Телдән аралашуның максатларын аңлау. Тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә төшенү, аның буенча сорауларга җавап бирү, әңгәмәдә катнашу.

Телдән сөйләм. Тел берәмлекләрен сөйләм ситуациясенә бәйле рәвештә сайлый белү. Диалогик һәм монологик сөйләмдә катнашу, аерым темалар буенча әңгәмә кору. Фикерне телнең орфоэпик һәм интонацион нормаларын саклап җиткерү; сөйләм әдәбе үрнәкләрен дөрес куллану.

**Уку.** Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген аңлап, орфоэпик нормаларны саклап, җөмләләрне синтагмаларга бүлеп, сөйләм яңалыгын белдергән кисәкләргә логик басым ясап, йөгерек укый белү. Текстның темасын һәм төп фикерен билгели алу. Аның эчтәлегенә һәм төзелешенә бәя бирү.

**Язу.** Грамотага өйрәтү чорында хәрефләр, иҗекләр, сүзләр һәм җөмләләр язу. Өйрәнелгән кагыйдәләргә туры килә торган текстны әйтеп яздыру һәм күчереп язу. Укылган һәм тыңланган текстның эчтәлеген, тулы итеп яки сайлап, язмача бәян итү. Балалар өчен кызыклы булган темаларга сюжетлы картина, әдәби әсәр, видеоязма фрагментын карагач, күргәннәргә нигезләнеп һ.б.ш. типтагы кечкенә күләмле үз текстыңны төзү.

### Грамотага өйрәнү

**Фонетика**. Авазлар. Әйтелгән сүздән аерым сузык яки тартык авазны ишетеп, аерып алу. Сүздәге авазларның санын һәм эзлеклелеген билгеләү. Бер яки берничә авазы белән аерыла торган сүзләрне чагыштыру.

Сузык һәм тартык авазларны, калын һәм нечкә сузыкларны, басымлы һәм басымсыз сузыкларны, яңгырау һәм саңгырау тартык авазларны аеру.

**Иҗек.** Иҗек калыплары. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, сүз басымын билгеләү.

**Графика.** Хәреф һәм аваз турында төшенчә. Сузык һәм тартык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар, аларны хәрефләр белән белдерү. Калын һәм нечкә әйтелешле сүзләрдә сузык авазларның роле. Е – ё, ю, я хәрефләренең кулланылышы. Калынлык (ъ) һәм нечкәлек (ь) билгеләренең кулланылышы.

**Уку**. Иҗекләп уку күнекмәләрен формалаштыру (сузык аваз хәрефләренә карап, сүзләрне калын һәм нечкә итеп уку). Әдәби әйтелеш нормаларын саклап, иҗекләрне һәм сүзләрне тиешле тизлек белән уку. Сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне һәм кыска текстларны аңлап уку; гади җөмлә ахырындагы тыныш билгеләренә игътибар итеп, тиңдәш кисәкләрне, эндәш сүзләрне тиешле интонация һәм пауза белән уку. Зур булмаган текстны һәм шигырьләрнең эчтәлеген аңлап, сәнгатьле итеп уку күнекмәләрен шомарту.

Сүзләрне укуга күчкәч, орфоэпик нормаларны саклау.
**Язу.** Язганда тиешле гигиена таләпләрен үтәү, кул һәм бармак мускулларының җитез һәм ритмик хәрәкәт итүләренә ирешү. Баш һәм юл хәрефләренең язылышын үзләштерү. Гигиена нормаларын саклап, хәрефләр, иҗекләр, сүзләр һәм җөмләләр язу. Әйтелеше белән язылышы арасында аерма булмаган сүз һәм җөмләләрне ишеткәнчә язу. Дөрес күчереп язу алымнарын һәм эзлеклелеген үзләштерү. Сүзләр арасында буш урын калдыру, юлдан-юлга күчерү билгесе кую кебек график чараларның функциясен аңлау.
**Сүз һәм җөмлә.** Сүз һәм аның лексик мәгънәсе. Сүзләрнең мәгънә ягыннан төрләрен күзәтү. Сүз һәм җөмләне аеру. Җөмлә белән эш: аерым сүзләрне табу, аларның урнашу тәртибен үзгәртү.
**Орфография.** Дөрес язу кагыйдәләре һәм аларның кулланылышы белән танышу:
сүзләрнең аерым язылуы;
о, ө хәрефләренең татар сүзләренең беренче иҗегендә генә язылуы;
җөмлә башындагы сүзне баш хәреф белән язу, җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләрен дөрес кую;
сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм юлдан-юлга иҗекләп дөрес күчерү.
**Сөйләм үстерү**. Укылган текстның эчтәлеген үзлегеңнән кычкырып укыганда яки тыңлаганда аңлау. Сюжетлы рәсемнәр, үзеңнең уеннарың, күзәтүләрең буенча хикәяләү характерындагы зур булмаган текстлар төзү.
**Систематик курс**
**Фонетика һәм орфоэпия**
Сузык һәм тартык авазларны аеру. Сүзләрдә басымлы һәм басымсыз сузык авазларны табу. Нечкә һәм калын тартык авазларны аеру, парлы һәм парсыз тартык авазларны билгеләү. Яңгырау авазларны аеру, аларның парларын билгеләү. Авазга өйрәнелгән күләмдә характеристика бирү: сузык-тартык; басымлы-басымсыз; калын-нечкә, яңгырау-саңгырау, парлы яки парсыз тартык. Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Авазларның хәзерге әдәби тел нормаларына туры килгән әйтелеше. Сүзгә фонетик анализ элементлары.
**Графика**
Аваз һәм хәрефне аеру. Язуда ъ һәм ь хәрефләрен куллану. Е – ё, ю, я хәрефләре булган сүзләрдә аваз һәм хәреф бәйләнешен билгеләү. Сүзләр арасында буш урын калдыру, юлдан-юлга күчерү билгесе кую, кызыл юл кебек график чараларны куллану.
Алфавиттагы хәрефләрнең исемен дөрес әйтү, аларның урнашу тәртибен белү. Сүзлекләр яки белешмәлекләр белән эшләгәндә, алфавиттан файдалана белү.
**Лексикология**
Сүзнең яңгыраш һәм мәгънә бердәмлеге булуын аңлау. Мәгънәсе төгәллек таләп итә торган сүзләрне ачыклау. Сүзнең мәгънәсен текст буенча яки аңлатмалы сүзлек ярдәмендә ачып бирү. Бер һәм күп мәгънәле, туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләрне табу. Сөйләмдә синоним һәм антонимнарның кулланылышына игътибар итү.
**Сүз төзелеше (морфемика)**
Тамырдаш сүзләр турында төшенчә булдыру. Тамырдаш сүзләрне бер сүзнең төрле формаларыннан аеру. Тамырдаш сүзләрне омонимнардан аеру. Сүзләрдә тамыр һәм кушымчаны аерып күрсәтү. Сүз ясагыч кушымчалар турында төшенчә бирү. Тамырдаш сүзләрнең сүз ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясалуы. Сүз төзелешен тикшерү күнегүләрен үтәү.
**Морфология**
Сүз төркемнәре турында төшенчә бирү. Исем, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Ялгызлык исемнәрне таба белү. *Кем?Нәрсә?* сорауларына җавап биргән исемнәрне аеру. Исемнәрнең сан формалары. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше, аларның килешләрен билгеләү. Килеш сораулары. Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. Исемнәргә морфологик анализ ясау.
Сыйфат, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Сыйфатның сораулары. Сыйфатның төс, тәм, форма, күләм, характер һ.б. билгеләрне белдерүе. Сыйфат дәрәҗәләре. Сыйфатның исемгә бәйләнеп килүе. Сыйфатка морфологик анализ ясау.

Алмашлык. Алмашлык турында гомуми төшенчә. Зат алмашлыклары, аларның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. I, II, III зат алмашлыклары, аларның берлек һәм күплек сан формалары, килеш белән төрләнеше.
Фигыль. Мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. *Нишли? Нишләде? Нишләр?* сорауларына җавап биргән фигыльләрне аеру. Фигыльнең зат-сан белән төрләнүе, төрле заман формалары (хәзерге, үткән, киләчәк заманнар). Фигыльнең барлык һәм юклыкта килүе. Фигыльләргә морфологик анализ ясау.
Рәвеш, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы.
Кисәкчәләр (*да, дә, та, тә, гына, генә, кына, кенә, ук, үк, ич, бит*). Аларның дөрес язылышы.

**Синтаксис**

Җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аеру, аларның охшаш һәм аермалы якларын аңлау. Әйтү максаты ягыннан хикәя, сорау, тойгылы һәм боеру җөмләләр, аларны дөрес интонация белән уку.
Җөмләнең баш кисәкләре. Баш һәм иярчен кисәкләрнең аермасы. Сүзтезмәдәге сүзләр һәм җөмлә кисәкләре арасында мәгънәви сораулар ярдәмендә бәйләнеш булдыру.
Теркәгечле (*һәм, ә, ләкин*) һәм теркәгечсез тиңдәш кисәкле җөмләләрне табу һәм мөстәкыйль рәвештә төзү. Тиңдәш кисәкле җөмләләрдә санау интонациясе.
Гади һәм кушма җөмләләрне аеру.

**Орфография һәм пунктуация**

Укучыларда орфографик зирәклек тәрбияләү.
Дөрес язу кагыйдәләрен куллану:
сузык аваз хәрефләрен дөрес язу кагыйдәләре;
тартык аваз хәрефләрен дөрес язу;
сүзне юлдан-юлга күчерү;
җөмлә башындагы беренче сүзне һәм ялгызлык исемнәрне баш хәреф белән язу;
калынлык (ъ) һәм нечкәлек (ь) билгеләрен дөрес язу;
һәмзә [ ’ ] авазын язуда белдерү;
җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләре кую;
тиңдәш кисәкләр арасында өтер кую.

**Сөйләм үстерү**

Аралашу ситуациясен – аралашу кем белән, кайда, нинди максат белән башкарылуын аңлау. Үз фикереңне әйтү һәм аны дәлилләү. Әңгәмә үткәрүнең төп күнекмәләрен үзләштерү (сүз башлау, әңгәмәгә кушылу, аны дәвам итү, игътибарны җәлеп итү һ.б.).
Уку, көндәлек аралашу шартларында тел әдәбе нормаларын үзләштерү (сәламләү, хушлашу, гафу үтенү, рәхмәтле булу, сорау белән мөрәҗәгать итү). Татар телен йомшаграк белүче кешеләр белән аралашканда сөйләм әдәбе үзенчәлекләре.
Билгеле бер темага караган төрле (сурәтләү, хикәяләү характерындагы) сөйләм текстлары кулланып, телдән монологик сөйләмне гамәли яктан үзләштерү.
Текст. Текст билгеләре. Тексттагы җөмләләрнең мәгънәви бердәмлеге. Текстка исем бирү. Тексттагы җөмләләрнең эзлеклелеге. Текст кисәкләренең (өлешләренең) эзлеклелеге, кызыл юл турында төшенчә.
Текстка исем бирү, җөмлә һәм текст кисәкләрен билгеләү, җөмлә һәм текст кисәкләре эзлеклелеген төзәтү.
Текстның планын төзү. Бирелгән план буенча үз текстыңны төзү.
Сурәтләү һәм хикәяләү характерындагы текстлар, аларның үзенчәлекләре.
Котлау тексты һәм хат язу. Язма сөйләмнең төгәллеген, дөреслеген һәм сәнгатьлелеген саклап, үз текстыңны төзү һәм бирелгән текстларны тикшереп төзәтү, текстта синонимнар, антонимнар куллану.
Изложение һәм сочинениенең төп төрләре белән танышу (билгеләмәләрен ятламыйча): бирелгән текстны тулысынча файдаланып яки аерым урыннарын (сүзләрен) сайлап алып языла торган изложение, сочинение элементлары булган изложение, хикәяләү-сурәтләү рәвешендәге сочинение һ.б.

**Укыту курсы темалары эчтәлеге:**

**1 сыйныф**
**Әлифба чоры**
Сузык авазлар
Сузык [а, ә, ы, э, и, у, ү, о, ө] авазларының сүздә төрле позициядә килгән һәм аерым кулланылган очрактагы артикуляцияләрен ныгыту. Сузык авазларны аеру күнегүләре. Иҗек ясау процессында сузыкларның роле. Сүз кисәге буларак иҗек турында белешмә. График схема буенча сузык авазны әйткәндә, сузыкка басым куеп әйтү. Сүзнең график схемалары буенча сүзне көйләп,иҗекләргә бүлеп салмак һәм орфоэпик дөрес уку. Сүзнең иҗекләргә бүленешен дуга ярдәмендә билгеләү.
Схемада сузык авазны башта түгәрәк, соңыннан транскрипция билгесе белән билгеләү. Ишетелгән һәм әйтелгән сүзләр арасыннан өйрәнелә торган аваз кергән сүзне таный һәм аера белергә өйрәнү. Өйрәнелгән сузык аваз кергән сүзләр сайлау.
Элемент-өлге ярдәме белән басма хәрефләр төзү һәм аларның формаларын үзләштерү. Хәреф турында авазның тышкы билгесе, ягъни «киеме» буларак образлы күзаллау булдыру.
Укытучы укыган текстны тыңлау, эчтәлеген аңлау, куелган сорауларга җавап табу, ишетеп кабул ителгән текстның эчтәлеген тулысынча яки сайлап сөйләү
**Парсыз сонор тартык авазлар**
[м, н, л, р, й, ң] сонор тартык авазлары. Бирелгән авазларның артикуляциясе : үпкәдән килә торган һава агымы бер сөйләм органында, мәсәлән иреннәрдә, тешләрдә, тел алдында, тел уртасында, тел артында киртәгә яки тоткарлыкка очрый, бу авазларны әйткәндә тон өстенлек итә, шау катнаша гына. Шуңа күрә ул авазларны ярым сузыклар дип тә йөртәләр. Калын һәм нечкә яңгырашлы сүзләрдә сонор тартык авазлар әйтелешен чагыштыру; язуда аларның калын яңгырашын калын сузык аваз хәрефләре (а, у, о, ы) белән (ма, му), нечкә яңгырашын нечкә сузык аваз хәрефләре (ә, и, ө, ү, э) белән белдерү. Сүздә һәр авазны аерып әйтү алымы. Рәсем һәм схема белән бирелгән сүзләргә аваз анализы. Анализлана торган сүз составына кергән аерым аваз артикуляциясе. Тартык авазларның яңгыраулыгын белдерүче билге — уртасында нокта булган квадрат белән билгеләү. Чагыштыру өчен бирелгән сүзләрдәге (мал-мәл) авазларның аермалы билгеләренең мәгънә функциясенә ия булуын билгеләү. Сонор авазларны белдерүче басма баш һәм юл хәрефләрнең формаларын үзләштерү. Ябык иҗекләрне (ай) һәм калын һәм нечкә яңгырашлы кушылмаларны (ма, мә, му, мү һ.б.), шулай ук парсыз тартык авазлар уртада һәм ахырда булган сүзләрне (май, малай) уку. Сүзләрне иҗекләп уку белән чагыштырып, орфоэпик уку һәм әйтү алымы.
**Сүз башында һәм сүз уртасында |й] авазы**
Я, е, ю хәрефләренең ике авазга [йа], [йә], [йы], [йә], [йу], [йү] билге булып килүләре: яра, ял, юл, куян, баян. Аваз-хәреф схемаларын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп уку. Шартлы билгеләр һәм басма хәрефләр нигезендә сүзнең аваз формасын график формага күчерү процессын күзәтү. Я, е, ю хәрефләрен куллану кагыйдәләрен үзләштерү. Бу хәрефләр кергән сүзләрне һәм иҗекләрне уку. Баш һәм юл басма хәреф формаларын төзү.
**Яңгырау һәм саңгырау парлары булган тартыклар**
Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны калын һәм нечкә яңгырашын билгеләү: нечкәлек яңгырау, саңгырау ([д-т],[з-с],[г-к],[гъ-къ] һ.б.) парларның үзара мөнәсәбәтен ачыклау. Мәсәлән бар-бар, бар-пар һ.б. Өйрәнү тәртибендә басма хәреф формаларын үзләштерү. Авазларында аерма булган сүзләрне, яңгырау һәм саңгырау тартык авазлардан башланган сүзләрне әйтеп карау, чагыштыру күнегүләре (бар-пар).
Аваз-хәреф схемалары нигезендә авазларны аеру, иҗекләр, сүзләр, текстлар уку. Башлангыч сүзне һәм сүзнең авазын алмаштыру яки аваз өстәү юлы белән ясалган яңа сүзләрне (бур-бура-буран), шулай ук ике яктан да бертөрле укыла торган (ана) сүзләрне уку. Табышмаклар уку һәм аларның җавабын табу. Тизәйткечләр, санамышлар, үртәвечләр, өйрәнелә торган аваз булган халык мәкальләрен уку, истә калдыру һәм хәтер буенча сөйләү. Аваз. иҗек.сүз.җөмлә һәм текст турында образлы күзаллау формалаштыру
**Парсыз тартык авазлар**

Парсыз [х, һ, щ, ц] тартыклар артикуляциясе. Бу авазларның характеристикасы. Парсыз тартык авазлар кергән иҗекләр һәм сүзләр, текстлар уку. Текстның эчтәлеген үзләштерү. Эчтәлеген сөйләү. Басма хәрефләрнең формаларын үзләштерү.
Аеру билгеләре булып торган ь һәм ъ тан соң [й] авазы (1 сәг)
Язуда аеру билгеләре булып торган ь һәм ъ һәм сузык аваз хәрефләре ярдәмендә [й] авазының язуда бирелешен (ь+е, я, ю; ъ+е, ю, я) аңлату. (Я, е, ю хәрефләре алдындагы иҗек калын сүзләргә (альяпкыч) ъ билгесе, алдагы иҗек нечкә сүзләргә (дөнья)ь билгесе куелуын аңлатыла).
Аеру билгеләре һәм сузык аваз хәрефләре белән белдерелгән [й] авазлы сүзләрнең аваз анализы. [Й] авазы кергән сүзләрнең аваз схемасын уку. аны хәреф формасына үзгәртү, соңыннан башта иҗекләп, аннан соң орфоэпик дөрес итеп уку. Ь, ъ билгеләренең басма хәрефләрен төзү һәм аларның формаларын үзләштерү. (Бу билгеләрнең [гъ], [къ] авазларының калынлыгын белдерү өчен дә кулланылуын аңлату (игътибар, тәкъдим).Калын [гъ] һәм [къ] авазлары булган сүзләрнең калынлыгын белдерү өчен язуда калын сузык аваз хәрефләре куланылуын, әйткәндә, иҗек нечкәлеген белдерү өчен, ахырдан ь билгесе куелуын ассызыклан үтәргә кирәк. Мәсәлән мәкаль сүзендә [къ] калын кече тел тартыгы, аның калынлыгын белдерү өчен к дан соң а язабыз, укыганда[мәкъәл]дип укыйбыз, икенче иҗекне нечкә итеп уку өчен сүз ахырына ь билгесе куябыз.) Ь, ъ билгеләренең басма хәрефләрен төзү һәм аларның формаларын үзләштерү.

**2 сыйныф:**
**Фонетика һәм орфоэпия** .Беренче сыйныфта алган белемнәрне, эш осталыгын һә күнекмәләрне ныгытып,тирәнәйтеп, гомумиләштереп, системалаштырып,лингвистик компетенция булдыруга нигез салу.Сузык һәм тартык авазларны дөрес аерып, сүзне иҗекләргә бүлеп,андагы авазларны ачык әйтеп, хәрефләрне дөрес атап, сүздә аваз-хәрефләрнең санын һәм эзлеклелеген билгеләү.
Калын һәм нечкә сузык авазларның икенче функциясен – сүзнең калын һәм нечкә әйтелешен билгеләү –гамәли үзләштерү Е,я,ю хәрефләренең сүз башында һәм сузык авазлардан соң ике аваз белдергән очракларын танып белү һәм шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес уку, күчереп язу.
Ъ ь хәрефләренең аваз белдермәгәнлеген истә тоту, шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес уку.
Баш һәм юл хәрефләрен дөрес куллануга күнегү һәм биремнәрне аңлап башкару.
Авазларның, сүз басымының мәгънә аеруда катнашуы, дәресләрдә өйрәнгән сүзләрне тиешле басым белән әйтү.
**Графика.**Татар алфавитын төгәл, хәреф исемнәрен дөрес итеп яттан белү.Төрле сүзлек һәм белешмәлекләр белән эшләгәндә, алфавиттан файдалану.Беренче хәрефенә карап, сүзләрне алфавит тәртибендә урнаштыру.
**Сүз.** Сүзнең предмет (кем? нәрсә?), хәрәкәт(нишли?) һәм билге (нинди?)атамасы булуы.Сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне аера белү.Сүзтезмә һәм җөмләләрнең сүзләрдән төзелүе.Һәр җөмләнең нинди дә булса максат белән әйтелгәненә гамәли күзәтүләр.Тамыр сүзләр.Татар телендә сүз тамырның сүз башында булуын, үзгәрмәвен, кушымчаларның тамыр сүзгә сингармонизм законына бәйле рәвештә ялганып килүен күзәтү.(җир ,җирле, җирлеләр, җирсезлек,)
Кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл ,елга, исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.
**Җөмлә.**Сөйләмне җөмләләргә аеру.Терминын кулланмыйча, җөмләнең нинди максат белән әйтелүенә күзәтүләр, шул максаттан чыгып, аңа дөрес интонациягә сайлау, хикәя, сорау җөмләләрнең азагында интонациягә бәйле рәвештә тыныш билгеләре куя белү
Җөмлә төзү алгоритмын гамәли үзләштерү
1.Җөмләнең үзеге итеп,нинди дә булса эш, шөгылҗ, хезмәт, эшчәнлек, хәл, хәрәкәт, хәбәр сайлау.
2.Моны кем башкара ала?
3.Бу эш, хәл, хезмәт, хәрәкәт кайда, кайчан, ничек булырга мөмкин?

Җөмлне төзүче баш кисәкләр . Ия һәм хәбәр.Аларны җөмләдә табу схемалар, сызыклар белән күрсәтү.Сораулар ярдәмендә җөмләдә сүзләр бәйләнешен билгеләү. Дәрестә укып тикшергән җөмләләрне ишетеп язу.

**Бәйләнешле сөйләм.** Бәйләнешле сөйләмдә җөмләләрне узара бәйләнеше.Бер темага берләштерелмәгән аерым җөмләләрне текст белән чагыштыру.Текстның темасын билгеләү.Текстны кисәкләргә бүлү, шул кисәкләрдән берләштерү чараларын текстлар эчендә күзәтү.Зур булмаган текстларга исем кую.Укыган әсәрнең эчтәлеген сөйләү.Сюжетлы рәсемнәр буенча хикәя язу.Җөмләләрне тиешле тәртиптә урнашттырылмаган кечкенә текстларны тикшерү һәм төзәтеп язып кую.Шигырь, мәкаль,әйтем табышмаклар ятлау.

Язма эшләр: сүзлек диктанты, искәртмәле диктант,сайланма диктант, күрмә диктант,хәтер диктанты,иҗади диктант,аңлатмалы диктант,ирекле диктант, контроль диктант.

**3 сыйныф:**

**Орфограмма .**Аваз һәм хәреф. Сузык һәм тартык авазлар.Иҗек.Сүзләрне юлдан юлга күчерү. ь,ъ хәрефләре кергән сүзләрне дөрес уку һәм язу. Янәшә килгән бертөрле аваз хәрефләре булган сүзләр.Алфавит. Алфавитның әһәмияте.Сүзлекләр белән эш.

**Сүз төзелеше**.Кушымча.Кушымчаларның төрләре.

**Сүз. Сүз төркемнәре**.Сүзнең лексик мәгънәсе.СинонимнарАнтонимнар Күп мәгнәле сүзләр. Искергән һәм яңа сүзләр.

**Исем.**Исем. Мәгънәсе, сораулары. Җөмләдәге роле Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр Ялгызлык исемнәрдә баш хәреф.Берлек һәм күплек сан формалары. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше

**Фигыль .**Мәгънәсе. Сораулары. Барлык, юклык формалары. Зат-сан белән төрләнүе**.** Хәзерге, үткән, киләчәк заманнар. Фигыльләрнең күпмәгънәлеге.

**Сыйфат**.Мәгънәсе,сораулары. Җөмләдә роле.Сөйләмдә әһәмияте.

**Алмашлык**.Зат алмашлыклары. Җөмләдәге һәм текстагы роле

**Кисәкчә**.Да. дә. гына , генә. Та, тә, ук, үк, кына ,кенә кисәкчәләре. Сөйләмдәге роле

**Бәйлек.** Исемнәрнең һәм зат алмашлыкларының бәйлекләр белән килүе

**Җөмлә.**Җөмлә төрләре. ( хикәя. сорау, өндәү) **.** Интонация буенча төрләре.Җөмләнең баш кисәкләре.Җөмләнең иярчен кисәкләре.Җөмләдә сүзләр бәйләнеше **.** Җыйнак һәм җәенке җөмләләр

**Сүзтезмә.**Сүзтезмәдә сүзләр бәйләнеше

**Текст. Бәйләнешле сөйләм**.Текстның темасы. Төп фикере. Бүлек башы.Текстларның төрләре. Текстагы терәк сүзләр .Изложение, сочинениелар язу. Сөйләм этикасы.

**4 сыйныф:**

**1-3 сыйныфларда үткәннәрне кабатлау.** Аваз һәм хәреф. Сузык һәм тартык авазлар.Иҗек.Сүзләрне юлдан юлга күчерү. ь,ъ хәрефләре кергән сүзләрне дөрес уку һәм язуЯнәшә килгән бертөрле аваз хәрефләре булган сүзләр.Алфавит. Алфавитның әһәмияте.Сүзлекләр белән эш.Сингармонизм законы турында беренче күзаллау.

**Сүз.** Телнең сүзлек байлыгы.Сүзнең лексик мәгънәсе . Сүз. Телнең сүзлек байлыгы. Тотрыклы сүзтезмәләр, омоним, синоним антоним,фрозеологик әйтелмәләр сүзлеге белән эш. Күп мәгнәле сүзләр. Искергән һәм яңа сүзләр

**Сүз төзелеше.** Кушымча.Кушымчаларның төрләре.Кушымчаларның ясагыч һәм төрләндергеч буенча ясалышы(кушма, парлы сүзләр)

**Сүз төркемнәре . Исем.** Исем. Мәгънәсе, сораулары. Җөмләдәге роле Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр Ялгызлык исемнәрдә баш хәреф

Берлек һәм күплек сан формалары. Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнеше.

**Фигыль** Мәгънәсе. Сораулары. Барлык, юклык формалары Зат-сан белән төрләнүе. Хәзерге, үткән, киләчәк заманнар. Фигыльләрнең күп мәгънәлеге.Боерык фигыль. Фигыльнең нигезе дифтонгка тәмамлануы. (сау-савыйм, савыйк, савыгыз)

**Сыйфат.**Мәгънәсе,сораулары. Җөмләдә роле. Сөйләмдә әһәмияте. Сыйфат дәрәҗәләре, сыйфатның җөмләдәге роле. (аергыч, хәбәр)

**Алмашлык .Зат алмашлыклары.** Җөмләдәге һәм текстагы роле. Сорау алмашлыклары.Килеш белән төрләнеше, дөрес язылышы.

**Сан** . Санның билгеләмәсе, сорауларымикдар саны, тәртип саны.

**Рәвеш** Лексик-грамматик яктан эш-хәлнең билгесен белдерүе.Аның төрләнмәве.Төп синтаксик функциясе – хәл.

**Кисәкчәләр** Да. дә. гына , генә. Та, тә, ук, үк, кына ,кенә кисәкчәләре. Сөйләмдәге роле. Аларның җөмләгә төрле төсмер өстәве.

**Бәйлекләр** . Төрле килешләрдә исемнәрнең һәм зат алмашлыкларының бәйлекләр белән килүенә йомгак ясау, системалаштыру.

**Җөмлә. Сүзтезмә .**Сүзтезмә һәм тезмә сүзләр арасындагы аерманы аңлату, сүзтезмәдәге иярүче һәм ияртүче сүз турында белемнәрне тирәнәйтү

**Җөмләнең баш кисәкләре. Ия һәм хәбәр.** Җөмләнең баш кисәкләре.

**Җыйнак һәм җәенке җөмләләр.** Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне аеру.

**Җөмләнең иярчен кисәкләре** . Аергыч. Аергычка билгеләмәне һәм аның белдерүен аңлату.

**Җөмләнең тиңдәш кисәкләре**. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Җөмләнең тиңдәш кисәкләрен һәм тиңдәш кисәкләрнең узара санау интонациясен, теркәгечләр ярдәмендә бәйләнеше.Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре.

**Эндәш сүзләр.** . Эндәш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләре.

**Гади һәм кушма җөмлә.** Тезмә кушма җөмләләрдә һәм, ә, ләкин, әмма теркәгечләре, алар янында тыныш билгеләре

**. Программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр.**

**1 нче сыйныф укучыларының белем дәрәҗәләрендә булачак нәтиҗәләр**

1 классны тәмамлаганда, укучылар татар телендәге барлык аваз һәм хәрефләрне гамәли танып белергә, аваз белән хәрефнең төп аермасын практик аңлауга ирешергә тиеш;

сүзләрне авазларга таркату, авазларны сүздәге тәртиптә әйтү;

сузык һәм тартык авазларны һәм аларның хәрефләрен аерып таный белү;

сүздән тыш та калын һәм нечкә сузыкларны дөрес әйтү;

сузык аваз һәм аларның хәрефләренә карап, калын һәм нечкә әйтелгән сүзләрне тану;

сүзләрне иҗекләргә бүлү;

җөмләләрне сүзләргә таркату;

баш һәм юл хәрефләрен, аларны тоташтыручы сызыкларны һәм сүзләрне ачык итеп, бозмыйча язу;

басма, язма хәрефләр белән бирелгән сүз һәм җөмләләрне дөрес күчереп язу;

әйтелеше белән язылышы туры килгән сүзләрне, шундый сүзләрдән төзелгән 3-5 сүзле җөмләләрне ишетеп дөрес язу;

җөмләнең беренче сүзен баш хәреф белән башлап, җөмлә беткәч, нокта куеп язу;

телдән 4-5 җөмләле кечкенә хикәяләр төзү;

сыйныфта телдән җыр, шигъри куплетлар, мәзәк , әкиятләр уйлап чыгаручыларны хуплау.

**2 нче сыйныф укучыларының белем дәрәҗәләрендә булачак нәтиҗәләр**

-сүзләрне,җөмләләрне, 30-40 сүзле текстны, хәрефләрен бозмыйча, төшереп калдырмыйча, хәреф өстәмичә, урыннарын алыштырмыйча, аңлаешлы, пөхтә итеп, каллиграфик дөрес язу

-сузык һәм тартык авазларны, калын һәм нечкә сузыкларны икеләнүсез аеру, анализ ясау, бирелгән теориягә таянып, аларга анализ ясау,бирелгән аваз схемасына,характеристика тиешле авазлар, сүзләр сайлау.

-сүзләрне иҗекләргә бүлү һәи иҗекләп юлдан-юлга күчерү, бә-рәң-ге, бәрәң-ге, бә-рәңге

- Кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл ,елга, исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.

-е,в,г,й,к,н,ң,о,ө,х,һ,э,ю,я хәрефләре, ый, йо,йө кушымчалары булган сүзләрне дөрес язу

-янәшә килгән бертөрле ике тартык аваз хәрефләре булган әллә, кәккүк.Габбас кебек сүзләрне, нечкә(калын) аеру билгесе кергән гади, программада булган сүзләрне (дөнья, ашъяулык) дөрес язу һәм юлдан –юлга күчерү
-сүзгә фонетик анализ ясау, иҗекләргә бүлү,авазларны сүздәге тәртиптә ачык, дөрес әйтеп атап чыгу,
-үзең язганны бирелгән үрнәк белән чагыштыру
-сүзләргә дөрес сорау кую һәм шуның нигезендә предметны ,предметның эшен,хәрәкәтен, билгесен, өстәмә предметны ,ярдәмче сүзләрне таба белү
-җөмләнең баш кисәкләрен таба бел-уку,уеннар, көндәлек тормыш, җәнлекләр, кош-кортлар турындагы темаларга 4-5 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп сөйләү һәм язу
сүзләрнең әйтелешен, кулланышын, язылышын истә калдыру: аваз,авыз, елга, бәрәңге, бияләй, борын, вакыт,гомер, гыйнвар, дөрес, дүшәмже, җавап, җомга,җөмлә,җылы,йөрәк,караңгы,көньяк,кыңгырау,маңгай,Мәскәү,муен,онык,оя,пәнҗешәмбе,савыт, сәгать,, сәлам, сеңел, тавык,тавыш, тәмле, төньяк, уен, уңыш,хайван,хөрмәт,һава,һаман,чаңгы,чәршәмбе,чия,шәһәр,шуа,эссе,юан,якшәмбе

**3 нче сыйныф укучыларының белем дәрәҗәләрендә булачак нәтиҗәләр**
-сүзнең мәгнәле кисәкләрен, тамыр һәм кушымча, ясагыч һәм төрләндергеч кушымчаларны аера һәм аларны сүзне кулланганда файдалана белү
-тамырдаш сүзләрне икеләнүсез аеру
-сүзләрнең төзелешен модель итеп күрсәтә белү, модель үрнәгендә яңа сүзләр ясау
-сүз төркемнәре: исем, сыйфат, фигыль алмашлык, кисәкчә, бәйлекләр
-җөмләнең баш кисәге, ия, хәбәр
-җөмләнең иярчен кисәкләре
-сузык һәм тартык авазларны, калын һәм нечкә сузыкларны икеләнүсез аеру, анализ ясау, бирелгән теориягә таянып, аларга анализ ясау,бирелгән аваз схемасына,характеристика тиешле авазлар, сүзләр сайлау.
-сүзләрне иҗекләргә бүлү һәи иҗекләп юлдан-юлга күчерү
-өйрәнгән орфограммалар кергән 55 -60 сүзле текстны, җөмлә ахырында тиешле тыныш билгеләрен куеп, диктант итеп язу, текстларны хатасыз һәм каллиграфик дөрес итеп күчереп язу
-сүз туркемнәрен һәм аларның грамматик билгеләрен тану, аеру(исемнең – санын, тартым кушымчалары булганда – затын, килешен, фигыльнең заманын, затын, санын)
- -сүзгә фонетик анализ ясау, иҗекләргә бүлү,авазларны сүздәге тәртиптә ачык, дөрес әйтеп атап чыгу,
-үзең язганны бирелгән үрнәк белән чагыштыру
-җөмләне анализлау: әйтү максаты, интонация буенча төре, баш һәм иярчен кисәкләр
Үзер яки бергәләп төзелгән план буенча 70-85 сүзле тексны изложение итеп язу, текстның темасын һәм фикерен чагылдыра алу, кызыл юлны саклау
Сөйләгәндә һәм язганда, текст өлешләре, җөмләләр арасында бәйләнеш булдыру.
Хикәяләү, тасфирлама, фикер йуртү тибындагы текстларны аера, төзи белү һәм кечкенә күләмле текстлар язып кую
-шәхси тәҗрибәгә, сюжетлы картина һәм рәсемгә таянып сочинение язу, сүзләрнең әйтелешен, кулланышын, язылышын истә калдыру.

**4 нче сыйныф укучыларының белем дәрәҗәләрендә булачак нәтиҗәләр**
-сүзләрдәге орфограммаларны танып, аларның язылышын кагыйдәгә нигезләнеп аңлату;
-үтелгән орфограммалар кергән 75-80 сүзле текстны хатасыз, каллиграфик күчереп һәм ишетеп, тиндәш кисәкләр янында тиешле тыныш билгеләрен дөрес куеп язу;
-дөнья, болыт тибындагы сүзләргә аваз-хәреф анализы ясау;
-сүзләрне төзелеше ягыннан тикшерү: тамырын һәм кушымчасын табу, кушымчаларның төрен билгеләү, кушма һәм парлы сүзләрне аерып күрсәтү;

-сүзләрне сүз төркеме булу ягыннан тикшерү: исемнең сан, килеш формасын күрсәтү; сыйфатның асыл, нисби төрен, чагыштыру дәрәҗәсен билгеләү; фигыльнең зат-сан, заманын аера белү; һәр сүз төркеменең җөмләдәге функциясен билгеләү;
-тиңдәшле кисәкле гади җөмләгә, составында 2-3 гади җөмлә булган тезмә кушма җөмләгә анализ ясау;
-җөмләләрнең әйтелү максаты, интонациясе буенча төрен аеру;
-текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү, шулар нигезендә аңа килешле исем кую;
-хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү тибындагы текстларны сөйләмдә куллану;
-әдәпле мөгаләмә таләпләренә туры китереп аралаша белү;
-тасвирлау, фикер йөртү элементлары кергән 90-95 сүзле текстны изложение итеп язу;
-хикәяләү тибындагы сочинение язу;
-сүзләрнең әйтелешен, кулланышын, язылышын истә калдыру: авыру, аз-маз,ата-ана,ашханә, аңлый,әби-бабай, әверелә, әүвәл,балачак, бәла, берничә, борынгы, вакыйга, ватык, гадәт, гомер, дәвам, җәяү, җепшек, җиләк-җимеш, зинһар,иелә, ихтирам, йомры, кадәр, кием-салым, кульязма, көнбатыш, көнчыгыш, көрәшче, кыйммәтле, мал-туар, мәйдан, мәкалә, могҗиза, мөстәкыйль, нәкъ,охшаш, очсыз, өем, өчпочмак, пәрәвез, рәссам, савыт-саба, сәнгать, сөңге, сурәт, табиб, табигый, таләп, тәкъдим, тәмам, тирә-як, төер, туп-туры, тынгылык, чүп-чар, шагыйрь, шәфәкъ, шыңшый, эшчән, юеш, юньле, юучы, ямьле, ямь-яшел, ять-яшь

<u>Тел системасы</u>
<u>Фонетика, орфоэпия һәм графика</u>
**Татар теленнән башлангыч гомуми белем бирү баскычын (1–4 сыйныфлар) тәмамлаган укучы:**
аваз һәм хәрефләрне аера;
ана теленең авазларын һәм хәрефләрен, аларның әйтелеш һәм язылыш үзенчелекләрен аңлый, авазларга характеристика бирә ала;
хәрефләрнең алфавитта урнашу тәртибен һәм, кирәкле мәгълүматны табу өчен, алфавитны куллана ала.
Укучыга дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча сүзгә мөстәкыйль рәвештә фонетик-график (аваз-хәреф) анализ ясарга өйрәнү, сүзгә ясалган фонетик-график анализның дөреслеген бәяләү мөмкинлеге бирелә.
Укучы:
үз сөйләмендә татар әдәби тел нормаларын саклый һәм әңгәмәдәшенең сөйләмендә бу нормаларның дәреслектә бирелгән материал күләмендә үтәлүен бәяли;
сүзгә басым куйганда яки сүзнең дөрес әйтелешендә икеләнү туган очракта, дәреслектәге сүзлек буенча мөстәкыйль рәвештә җавап таба яки укытучысына һәм эти-әнисенә мөрәҗәгать итә ала.
Сүз төзелеше (морфемика)
Укучы:
тамырдаш сүзләрне һәм сүз формаларын аерырга;
сүзнең тамыр һәм кушымчаларын (аффиксларын) табарга өйрәнә.
Укучы дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча кушымчаларның чикләре ачык күренеп торган сүзләрнең төзелешен тикшерү һәм аның дөреслеген бәяләү мөмкинлеге ала.

<u>Лексикология</u>
Укучы:
мәгънәсе ачыклану таләп итәлә торган сүзләрне табарга;
текст буенча сүзләрнең мәгънәсен аера яисә аны аңлатмалы сүзлек ярдәмендә ачыкларга өйрәнә.
Укучы, текстларда кабатлаулар булдырмас өчен, кирәкле синонимнар, антонимнар табу, текстта туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләрне билгеләү, аларның урынлы кулланылышын бәяләү, тәкъдим ителгән сүзләр арасыннан тиешлесен сайлап алу мөмкинлеге ала.
Морфология

Бу бүлектә укучы:
исемнәрнең сан, килеш һәм тартым белән төрләнешен;
сыйфатларның лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләрен;
фигыльнең лексик-семантик үзенчәлекләрен өйрәнә.
Укучы дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча исемгә, сыйфатка, фигыльгә морфологик анализ ясау һәм аның дөреслеген бәяләү, тексттан алмашлык, рәвеш, бәйлек сүзләр, кисәкчә, теркәгечләрне, фигыльләрдәге юклык кушымчаларын (-ма / -мә) табу мөмкинлеге ала.

Синтаксис

Бу бүлектә укучы:
җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аерырга;
сораулар ярдәмендә сүзтезмә һәм җөмләләрдәге сүзләр арасындагы бәйләнешне табарга;
җөмләнең әйтү максаты буенча төрен аерырга;
җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләргә;
тиңдәш кисәкле һәм тойгылы җөмләләрне интонациясе буенча билгеләргә өйрәнә.
